**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ XXV СЕССИЯСЕ**

# КАРАР № 147

Мөслим авылы «05» май 2023 ел

**«Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына милеккә һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль милек исемлеген раслау турында» 2016 елның 26 сентябрендәге 50 номерлы Мөслим муниципаль районы Советы карары белән расланган кече һәм урта эшкуарлык субъектларына милеккә һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль милек исемлегенә өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендага алынган күчемсез милекне читләштерү үзенчәлекләре турында 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү», Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Уставының 37 статьясы, кече һәм урта эшкуарлык субъектларының торак булмаган биналарга ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатыннан, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына милеккә һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль милек исемлеген раслау турында» 2016 елның 26 сентябрендәге 50 номерлы Мөслим муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Муниципаль милек исемлегенә әлеге карарга кушымта нигезендә түбәндәге объектларны кертергә һәм расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мөслим муниципаль районы башлыгы урынбасары А.М. Әхмәтҗановка йөкләргә

Мөслим муниципаль районы Башлыгы,
Мөслим муниципаль районы Советы рәисе А.Р.Хуҗин